**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге башлыгы**

**КАРАР**

**16 октябрь, 2020 ел.** **№ 2**

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Шәрбән авыл җирлегендә
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм алардан файдалану
мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 ел, 28 июль, 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Шәрбән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 ел, 28 октябрь, 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Аксубай районы Шәрбән авылы Лермонтов урамы, 6 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлегенең Шәрбән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020 елның 28 октябрендә 14.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Аксубай районы Шәрбән авылы, Лермонтов урамы, 6 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлегенең Шәрбән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлегендә яшәүчеләрнең исемлеген 2 өлешкә бүләргә:

1) Лермонтов урамы, Крылов урамы, Яшел урамы, Октябрь урамы, Совет урамы, М.Җәлил урамы, Газ урамы

2) Беренче май урамы, Кыр урамы,Пролетар урамы, Тукай урамы, Пушкин урамы, Үзәк урамы, Вахитов урамы, Елга урамы

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, беренче төркем инвалидлардан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертү һәм алдагы эшләрне башкару буенча әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

**1. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына һәм җирлек торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге:**

*- Шәрбән авылы Вахитов, Кыр, Пролетар, Яшел урамнары юлларын ремонтлау (вак таш, грунтлау һәм түшәү, килешү буенча түләү)*

**2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә, җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**

*- Полевая урамы, 11А адресы буенча урнашкан скважина өчен тирән насос алу.*

“ӘЙЕ” “ЮК”.

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда белдерү тактлары һәм стендларда урнаштыру юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә

Аксубай муниципаль районы
Шәрбән авыл
җирлеге башлыгы Д.Ә.Шәрифуллин